# “Иң зирәк яшь биолог” бәйгесе

# I раунд

## Дөрес җавапны сайларга

Очарга сәләтле түбәндәге тереклек ияләре арасыннан кайсысы канатларын иң еш җилпүче санала?

- а) озынборын
- б) умарта корты
- в) энә карагы
- г) ярканат

Чагыштырмача тыныч хәлдә торганда кеше йөрәге минутына 70-80 мәртәбә тибә. Ә шулай да түбәндәге җан ияләренең кайсысының пульс ешлыгы иң зурысы?

- А) эт
- Б) мәче
- В) йорт куяны
- Г) тычкан.

Кеше күп кенә хайваннарны, шул исәптән бөҗәкләрнең ике төрен кулга ияләштергән, ягъни йортлаштырган. Аларның берсе-умарта корты, икенчесе-...

- А) тут ефәкчесе
- Б) кырмыска
- В) таракан
- Г) борча

# Бамбук-ул...

- А) агач
- Б) куак
- В) үлән
- Г) мүк

Бәрәңге бүлбеләре- болар үзгәргән...

- А) җимешләр
- Б) тамырлар
- В) бәбәкләр
- Г) чәчәкләр

Нинди имезүче хайван бер күзен ачып йоклый?

- А) сыер
- Б) дельфин
- В) керпе
- Г) пингвин

Тундрада һәм тайгада умарта кортлары һәм төклетуралар очрамый. Алай булгач, поляр түгәрәк артында үсемлекләрне серкәләндереп аларга тереклекне кемнәр бирә?

- А) черкиләр
- Б) озынборыннар
- В) кошлар
- Г) җәнлекләр

# Хәзерге типтагы беренче кешеләр.

- А) дриопитеклар
- Б) неандерталецлар
- В) кроманьонецлар
- Г) австралопитеклар

# Боларның кайсысы артык?

- А) горилла
- Б) шимпанзе
- В) орангутанг
- Г) павиан

Безнең якларда яшәүче түбәндәге хайваннарның кайсысы кышкы йокыга талмый?

- А) керпе
- Б) бурсык
- В) үр куяны
- Г) йомран

Бездә яшәүче түбәндәге йорт хайваннарыннан кайсысының баласы сукыр килеш туа?

- А) эт
- Б) песи
- В) сарык
- Г) дуңгыз

Түбәндәге хайваннарның кайсысы АКШ тагы Республика партиясе символы булып тора?

- А) Каракош
- Б) фил
- В) арыслан
- Г) аю

Кайсы агач яфраклары яңгыр алдыннан 3-4 тәүлек алдан яшь «коя» башлый?

- А) өрәңге
- Б) имән
- В) каен
- Г) миләш

Безнең якларда үсүче түбәндәге үсемлекләрнең кайсысы йодка баерак?

- А) кабак
- Б) кәбестә
- В) кызыл чөгендер
- Г) кыяр

# II раунд

# Сорауларга җавап

# 56536545230

| | | |
|---|---|---|
| **1<br>АӘБВ** | **2<br>ГДЕ** | **3<br>ЖҖЗИ** |
| 4<br>КЛМ | 5<br>НОӨП | 6<br>РСТ |
| 7<br>УҮФХ | 8<br>ҺЦЧШ | 9<br>щЪЫЬ |
| | 0<br>ЭЮЯ | |

| Кошлар | Агачлар | Бөҗәкләр |
| --- | --- | --- |
| Чәчәкләр | Иң-иң... | Җәнлекләр |
| Җир-су хайваннары | Сөйрәлүче ләр | Суалчаннар |
| Балыклар | Кызыл китап | Әкият дөньясы |

# III раунд

# Сорауларга җавап

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| 20 | 20 | 20 | 20 | 20 |
| 30 | 30 | 30 | 30 | 30 |